**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**16.05.2022** **№ 489**

**«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга – товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар, бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең актларының кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» карарына таянып, сөт җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында, шулай ук Биектау муниципаль районында сыерларның баш санын саклап калу һәм арттыру буенча чаралар үткәрү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны интернет челтәрендә муниципаль берәмлекләр порталында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырып, халыкка игълан итәргә

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М. Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы
Башкарма комитетының
16.05.2022 489нче номерлы
карары белән расланды

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм (яисә) нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга (өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба – субсидияләр, ШЯХ, алучылар).

1.2. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты турында Биектау муниципаль районы Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет), әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын алучы буларак, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Субсидияләр бирү буенча бюджет акчаларын баш бүлүче булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

1.4. Гражданнарга субсидияләр максатчан характерда, түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бермәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга бирелә.

## 2. Субсидия алу өчен ШЯХларны сайлап алу категорияләре һәм критерийлары

2.1. Субсидия алучылар булып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары тора.

2.2. Субсидия бирү турында Карар кабул итү өчен сайлап алу критерияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлеге булу;
- агымдагы финанс елында таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуны раслаучы документлар һәм сатып алына торган терлеккә ветеринария документлары булу;
- сатып алына торган терлек өчен ветеринария документлары;

- субсидия алган көннән өч ел эчендә таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналарның баш санын саклап калу буенча йөкләмә (субсидия алу көне булып ШЯХ алып баручы гражданның банк счетына акча керү тора).

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның милкендә яңа сатып алганнардан тыш 2 һәм аннан да күбрәк сыер бар, (агымдагы елның 1 июленә);

- салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча гражданның Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле бурычлары булмау турында белешмә булу.

2.3. Субсидия шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр бирү өчен гариза биргән вакытта түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта бирелә:

- законнарда билгеләнгән тәртиптә хуҗалык кенәгәсендә теркәлү һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бару;

- әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан акча алучы булып тормый;

2.4. Агымдагы финанс елында юридик зат статусына ия авыл хуҗалыгы оешмаларыннан һәм (яки) крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан товарлыклы һәм (яки) нәселле таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алу.

## 3. Субсидияләр бирү шартлары

3.1. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга Субсидия, яңа сатып алынган бер баш өчен исәп-хисап ясап, бер тапкыр бирелә:

- товарлыклы тана һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган тана – 30 000 сум;

- нәселле тана һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган тана – 40 000 сум.

3.2. Субсидия күләме, транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча, бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка биш баштан артмаган сатып алынган товарлыклы һәм (яки) нәселле таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алу бәясеннән, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, 70 процентыннан артмаска тиеш.

3.3. Субсидия алу хокукын алу өчен гражданин (гражданка) Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документлар белән Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә гариза бирә:

- Россия Федерациясе гражданы паспортының күчермәсе;

- ИНН күчермәсе;

- таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналар сату-алу (җибәрү) шартнамәләренең күчермәләре, сату-алу шартнамәсе буенча түләүне раслаучы түләү документлары, таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга кабул итү-тапшыру акты, исемен, яшен күрсәтеп;

Искәрмә: сатып алына торган таналарның (21 айдан, тере авырлыгы 430 килограммнан да ким булмаган) һәм бер мәртәбә бозаулаган таналарның яше (27 айдан (36 айдан да өлкәнрәк түгел), тере авырлыгы 450 килограммнан да ким булмаган.

- сатып алына торган терлеккә озатучы ветеринария документларының күчермәсе;

- ШЯХ алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокук билгели торган документның (таныклык) күчермәсен яисә ЕГРНнан өземтә;

- сатып алынган терлекләрне исәпкә алу фактын раслаучы шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

- сатып алына торган нәселле таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналар нәсел таныклыкларының күчермәләре (нәселле терлекләр сатып алган очракта);

- дәүләт нәсел регистрында (нәселле терлекләр сатып алган очракта) токымлы терлекләр сатучы оешмаларны теркәү турында таныклык күчермәләре.

3.4. Сатып алынган товарлыклы һәм (яки) нәселле таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналар үлгән яки суелырга мәҗбүр булган очракта, авыру нәтиҗәсендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларның баш санын саклап калу буенча кабул ителгән йөкләмә вакыты чыкканчыга кадәр Башкарма комитетка ветеринария белешмәләре һәм терлекләрне билгеләнгән тәртиптә яраксызга чыгару актлары тапшыралар.

3.5. Тапшырылган документларның күчермәләре алучылар тарафыннан раслана.

3.6. Әлеге тәртип буенча социаль ярдәм чараларын алу шарты булып шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү тора.

3.7. Башкарма комитет:

- календарь көннәрендә исәпләнә торган 60 (алтмыш) көн дәвамында ШЯХ тапшырган документларны, алар кергән көнне, чират нигезендә, кабул итә һәм журналда терки, ул номерланырга, шнурланырга һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

-30 (утыз) көн дәвамында, эш көннәрендә исәпләнә торган документларны карый һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында Карар кабул итә;

- субсидия алучылар белән әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә субсидия бирү турында килешү төзи.

3.8. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

- тулы булмаган документларны тапшыру яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

- бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

3.9. Бюджет йөкләмәләре лимиты җитмәгән очракта, субсидияләр гаризалар бирү чираты тәртибендә бирелә.

3.10. Субсидияләр бирүдән баш тарткан очракта, Башкарма комитет эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта шәхси ярдәмче хуҗалыкларга бу хакта, 3 нче кушымта нигезендә, хәбәр җибәрә.

3.11. Субсидия алучы, субсидия алган көннән алып, нәселле таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналарның баш санын 3 (өч) ел дәвамында, үз

чиратында, товарлыклы баш санын 1 (бер) ел дәвамында саклап калырга бурычлы.

Сатып алынуына субсидия бирелгән таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар суелырга тиеш түгел (рөхсәт белән һәм ветеринария хезмәте белгече контролендә һәм тиешле документлар белән расланган очрактан тыш), сатылырга, файдалануга тапшырылырга, бүләк ителергә, алмашуга, пай, кертем рәвешендә взноска, яки башка ысул белән читләштерелергә нәселле баш саны буенча субсидия алган көннән башлап 3 (өч) ел дәвамында, товар баш саны буенча 1 (бер) ел дәвамында тиеш түгел.

## 4. Субсидия бирү тәртибе

4.1. Субсидия алу өчен Башкарма комитет субсидияләр алу хокукына ия гражданнарның җыелма реестрын билгеләнгән форма буенча Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендә формалаштыра һәм тапшыра.

4.2. Субсидияләр бирү Килешүгә кул куелганнан соң 14 (ундүрт) эш көне эчендә Биектау районы Башкарма комитетының шәхси счетыннан гражданнарның шәхси счетларына акча күчерү юлы белән субсидияләр бирү турындагы килешү Нигезендә башкарыла.

## 5. Бюджет акчаларын максатчан файдалану буенча хисаплылыкка таләпләр

5.1. Нәселле терлекләр буенча 3 (өч) ел дәвамында һәм товарлыклы терлекләр буенча 1 (бер) ел дәвамында, товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга субсидия алганнан соң, хисап елыннан киләсе елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, субсидия алучы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына сыерларның баш санын саклап калу күрсәткечләре буенча, әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә хисап бирергә тиеш.

5.2. Биектау муниципаль районы бюджетыннан бирелгән субсидияләр, субсидия алучы тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирелгән һәм субсидия бирү шартларын бозган очракта, Биектау муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

5.3. Гражданнар бирә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидияләр алу өчен мөрәҗәгать итүче булып торган гражданнарга әлеге Тәртип нигезендә йөкләнә. Коррупциягә каршы законнарны үтәү Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затларына йөкләнә. Закон бозучыларга гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

## 6. Аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта субсидияләрне кире кайтару тәртибе

6.1. Субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр тапшырган очракта, Башкарма комитет биш эш көне эчендә субсидия алучы адресына Биектау муниципаль районы бюджетына субсидияне кире кайтаруны таләп куя.

6.2. Субсидия алучы, таләпне алганнан соң утыз эш көне эчендә Биектау муниципаль районы бюджетына алынган субсидия суммасын кире кайтарырга тиеш, ул муниципаль район бюджеты керемена күчерелергә тиеш.

6.3. Күрсәтелгән срокка субсидияләр кайтмаган очракта, Башкарма комитет Биектау муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасын суд тәртибендә түләттерү буенча чаралар күрә.

6.4. Субсидияләр алган көннән алып өч ел эчендә таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналарның баш санын саклап калу буенча йөкләмәләр бозылган очракта, Башкарма комитет субсидия алучыга биш эш көне эчендә субсидияне муниципаль район бюджетына кайтаруны таләп итә.

6.5. Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тоту, бюджет акчаларын баш бүлүче буларак, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан башкарыла.

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы
Башкарма комитетының 16.05.2022
489нче номерлы карары белән
расланды

Биектау муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесе
______________________________________
кемнән________________________________
____________________________________
____________________________ яшәүче
паспорт серия ___№ ___________;
ИНН ______________________________
конт.
тел.
______________________________________

**ГАРИЗА**

Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 20___ елның _______ карары белән расланган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирүегезне сорыйм.

Шуны җиткерәм: ________________________________________адресы буенча урнашкан шәхси хуҗалыкта савым сыерларының саны

20___елның «___»____торышы буенча____________________

(____________________________________баш тәшкил итә.

1. Субсидия бирү тәртибе шартлары белән таныштырылдым һәм килешәм.

2. Субсидия бирелгән очракта, сүз бирәм:

а) Субсидия алганнан соң өч ел эчендә сөт сыерларының баш санын саклап калырга;

Гаризага кушымта итеп бирәм:

- Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе;

- ИНН күчермәсе;

- таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналар сату-алу шартнамәләренең күчермәләре, сату-алу шартнамәсе буенча түләүне раслаучы түләү документлары, таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга, исемен һәм яшен күрсәтеп, кабул итү-тапшыру акты;

- сатып алына торган терлек ветеринария озатучы документлары күчермәсен;

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокук билгели торган документның (таныклык) күчермәсен яисә ЕГРНнан өземтә.

- сатып алынган терлекләрне исәпкә алу фактын раслаучы шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

- сатып алына торган нәселле таналар һәм (яки) бер мәртәбә бозаулаган таналарның нәсел таныклыклары күчермәләре.

- дәүләт нәсел регистрында нәселле терлекләр сатучы оешмаларны теркәү турында таныклыкларның күчермәләре.

Субсидияне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүегезне сорыйм:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Субсидия бирү тәртибе шартлары белән таныштырылдым һәм килешәм.

__________________ /____________________/ «____» ___________,2020ел

**(имза)** **(Ф.И.А.)**

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданга субсидияне максатчан файдалану турында
**йөкләмә**

Мин, ______________________________________________________________________,

Паспорт сериясе ______________ № _____________________, ____________________________________________________________тарафыннан бирелгән, түбәндәге адрес буенча яшәүче :___________________________________________________________

____________________________________________________, ИНН______________,

**йөкләмә алам:**

1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелгән субсидияләрне үзләренең түбәндәге адрес буенча урнашкан: ______________________________________________________________________ _____________________________________________________________________ шәхси ярдәмче хуҗалыгында савым сыерлары асрауга катгый максатчан тотарга.

2. Алынган субсидияләрнең максатчан кулланылышын тикшерү өчен, Конкурс комиссиясе әгъзаларына шәхси ярдәмче хуҗалыкка киртәләрсез керү мөмкинлеген бирергә, субсидияләрдән файдалану турында кирәкле мәгълүмат бирергә.

3. Товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар тоту буенча хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырырга, субсидия алганда игълан ителгән нигездә булган баш санын, субсидия алганнан соң кимендә 3 календарь ел эчендә нәселле, үз чиратында товарлыклы баш санын 1 (бер) ел дәвамында киметмәскә.

4. Йөкләмәнең 1-3 пунктлары үтәлмәгән очракта һәм кул куелган йөкләмәнең шартларын үтәмәгән очракта -алынган субсидияне максатсыз куллану акты төзелгән көннән соң утыз эш көне эчендә алынган субсидияне авыл җирлеге бюджетына кире кайтарырга.

Әлеге йөкләмәгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр, алар язма рәвештә башкарылган һәм Яклар тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була. Әлеге йөкләмәдә җайга салынмаган барлык очракларда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нормалары кулланылачак. Әлеге йөкләмәне имзалаганда, Яклар анда аңлашылмаучанлыклар һәм билгеләмәләр булмавын белдерә.

Мин, ______________________________________, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге йөкләмәне төзегәндә һәм үтәгәндә бирелгән шәхси мәгълүматларга кагылышлы мәгълүматны эшкәртүгә ризалык белдерәм. Әлеге килешү төзелгән йөкләмәнең гамәлдә булу срогына (кул куелганнан соң 3 ел) бирелә.

«_____»______________________ 20____ел

______________________/______________________/ (имза)
(Ф.И.А.)

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының16.05.2022 489нче номерлы карары белән расланды

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү турында**
**КИЛЕШҮ**

___________
«__» __________20___ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Башкарма комитет җитәкчесе _____________________________________________ йөзендә, _____________________________________ нигезендә эш итүче, алга таба «Башкарма комитет» дип аталачак, бер яктан, һәм _____________________________________________________________________________, алга таба "Алучы" дип аталучы, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, әлеге килешүне (алга таба -Килешү) түбәндәгеләр турында төзеделәр:

**1. Килешүнең предметы**

1.1. Килешүнең предметы булып шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тора.
1.2. 20___ елда Алучыга бирелә торган субсидия күләме _________________________________________________________________ сум тәшкил итә.

**2. Якларны хокуклары һәм бурычлары**

2.1. Башкарма комитет йөкләмә ала:
а) Алучыга _____________ күләмендә субсидия бирергә;
б) әлеге Килешү кысаларында алынган субсидия Алучыны сыерларының баш санын кирәк булган саен тикшерергә.
в) Алучыдан әлеге Килешү предметына кагылышлы документларны һәм материалларны соратып алырга.
г) субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерергә.
2.2. Гариза бирүче бурычлы:
- субсидия алганнан соң өч ел эчендә сыерларның баш санын саклап калырга;
- Башкарма комитет субсидияләрнең максатчан кулланылышын тикшерү үткәргәндә, барлык кирәкле документларны һәм мәгълүматны тапшырырга;

- сатып алынуына субсидия бирелгән таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналарны суймаска (рөхсәт белән һәм ветеринария хезмәте белгече контролендә һәм тиешле документлар белән расланган очрактан тыш), сатмаска, алмаштырмаска, бүләк итмәскә, башка затларга файдалануга тапшырмаска, һәм башка ысул белән читләштермәскә;
- ел саен субсидия алу датасыннан 3 ел дәвамында 15 гыйнварга кадәр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына шәхси ярдәмче хуҗалыгында асрала торган авыл хуҗалыгы хайваннары турында хуҗалык кенәгәсеннән өземтә тапшырырга.

2.4 Субсидия алучы субсидияләр биргән бюджет акчаларын баш бүлүче һәм муниципаль финанс тикшерү органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру белән килешә.

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Әлеге килешү шартларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә субсидия бирелгән Нигезләмә нигезендә җаваплы булалар.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу срогы

4.1. Әлеге Килешү ике Як та кул куйган көннән үз көченә керә һәм әлеге Килешү буенча Якларның барлык йөкләмәләре беткәнче гамәлдә була.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәү барышында яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр (каршылыклар) алар, мөмкин булганча, сөйләшүләр уздыру, хатлар һәм башка документлар алмашу юлы белән яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Әлеге Килешү Якларның һәркайсы өчен бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

5.3. Килешүгә барлык кушымталар аның аерылгысыз өлеше булып тора.

## 6. Якларның адреслары һәм реквизитлары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | Субсидия алучы |
| Җитәче ____________/(Ф.И.А.)<br>М.У | ____________/(Ф.И.А.)<br>М.У |

3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 16.05.2022 489нче
номерлы карары белән расланды

___________________________________________

____________________________________________

Гариза бирүченең контакт белешмәләре

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирүдән баш тарту турында ХӘБӘРНАМӘ.**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Сезгә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирүдән түбәндәгеләр нигезендә баш тарту турында хәбәр итә:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

________________________________________________________________

Җитәкче _______________

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 16.05.2022 489нче
номерлы карары белән расланды

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия алуга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар**

**РЕЕСТРЫ**

**20**_____________елның «___» ______нә

| № | Гариза бирүченең Ф.И.А. | ИНН | Паспорты сериясе, номеры | Яшәү урыны адресы, Яшәү урыны буенча теркәлүе | ШЯХ та сыерлар саны, агымдагы ел башына | ШЯХ та сыерлар саны, гариза бирү датасына | Банк реквизитлары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Җитәкче ______________

5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 16.05.2022 489нче
номерлы карары белән расланды

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга субсидия алучы гражданнарның сыерлар баш санын саклап калу күрсткечләре буенча**
**хисап**

| Ф.И.А. | ИНН | Урнашу урыны адресы | Терлек саны | |
|---|---|---|---|---|
| | | | субсидия алу датасына | ____________ на (хисап бирү датасы) |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Җитәкче ______/________